| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

_02.12.2020__________ _1327-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 2 октябрендәге 561-п номерлы, 2016 елның 17 октябрендәге 1103-п номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 553-п номерлы, 2019 елның 5 февралендәге 89-п номерлы, 2019 елның 2 декабрендәге 1317-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) үзгәреш кертеп, аны кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенә (А.М. Чинарев) югарыда күрсәтелгән Регламент нигезендә эшләрне башкаруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэминат бүлегенә (А.И. Ткачук) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
22.11.2012 ел, № 489-п боерыгы
(2020 елның 2 декабрендәге
1327-п боерыгы редакциясендә)
белән расланды

# Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза тапшырган эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар, әгәр дә федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы
һәр көнне, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «Филармония» тукталышына кадәр килергә:

- 2, 4, 5, 31, 37, 43, 47, 67, 74, 74а, 77 санлы автобуслар;
- 6, 8, 12 санлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсенең җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: (843) 267-68-68.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.eco.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru); Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/); Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла: җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия (алга таба – Лицензия) – хуҗасы тарафыннан алдан ук сөйләшенгән шартлар үтәлгән очракта, билгеләнгән срок дәвамында анда күрсәтелгән максатка ярашлы рәвештә билгеле бер чикләрдә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия хуҗасы хокукын таныклый торган, вәкаләтле дәүләт хакимияте органы тарафыннан бирелә торган документ;

лицензия килешүе (килешү) – лицензиягә нигезләнгән һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат арасында килешү;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү – нефть, газ һәм башка матдәләр һәм материаллар саклау, шул исәптән радиоактив, зыянлы һәм агулы матдәләр һәм эшчәнлек калдыкларын күмү, агынты суларны ташлау (шул исәптән зыянлы һәм агулы матдәләр булганын да), торбаүткәргечләр һәм башка корылмалар төзү максатында рациональ эшкәртү тирәнлегенә кадәр файдалы казылмаларны ачыклау өчен перспективалы булмаган җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты корылмалары төзү һәм файдалану;

файдалы казылма – материаль җитештерү өлкәсендә нәтиҗәле файдалана алырлык җир кайрысында барлыкка килгән табигый минераль катлам;

запаслар – геологик-разведка (тау, бораулау, сынау) эшләре нәтиҗәсендә исәпкә алынган һәм санап чыгарылган файдалы казылма тупланмаларының күләме һәм саны;

җир асты байлыкларыннан файдаланучы – җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясе булган эшкуарлык эшчәнлеге субъекты, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар, әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса.

җир асты байлыкларыннан файдалану – җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару, җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, җир асты суларын эзләү һәм чыгару максатларында яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында, җирле әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге – гомумтаралган файдалы казылмаларны үз эченә алган җир асты байлыклары кишәрлеге яки файдалы казылмалар алуга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен кулланыла торган җир асты байлыклары кишәрлеге, яисә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү (алга таба – эчә торган су белән тәэмин итү) яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм табу күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган, шулай ук бакчачылык коммерциясез ширкәтләрен һәм (яки) яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрен эчә торган яки техник су белән тәэмин итү максатлары өчен җир асты сулары булган җир асты байлыклары кишәрлеге;

җир асты суы – җир асты байлыкларында булган, эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү (алга таба – эчә торган су белән тәэмин итү) яки техник су белән тәэмин итү максатлары өчен файдаланыла торган һәм алу күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган, шулай ук бакчачылык коммерциясез ширкәтләрен һәм (яки) яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрен (алга таба – Ширкәтләр) эчә торган су белән яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган су;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең,

белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр округының яки муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә оештырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать дигәндә (алга таба – рәсми мөрәҗәгать) 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла. Рәсми мөрәҗәгатьнең формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү турында карарлар кабул итү | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2359-1 номерлы Россия Федерациясе законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ законы) 16 статьясының тугызынчы абзацы; Югары Совет Нигезләмәсенең 1 пунктындагы 4 абзацы РФ № 3314-1; «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы |

| | | |
|---|---|---|
| | | Законының 7 статьясы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законы) |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.11 пунктының 14 абзацы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензияне мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә бирү.<br>2. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукына лицензия бирүдән баш тартудан нигезле баш тарту турындагы хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).<br>3. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән, лицензиягә кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләне үз эченә алган кушымтаны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә бирү.<br>Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергәндә җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары яңадан каралырга тиеш түгел.<br>4. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән нигезле баш тарту турында хатны гариза бирүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булган очракта аның законлы вәкиленә тапшыра (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү). | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $10^{1}$ статьясының 6 пункты, 11, $17^{1}$, 20, 21 статьялары, «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 21 статьясы<br>РФ Югары советы Нигезләмәсе, «Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. Җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә бирү.<br>6. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән нигезле баш тарту турындагы хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).<br>7. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар һәм мөрәҗәгать итүчегә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү яки мөрәҗәгать итүченең яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә кулга тапшыру.<br>8. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан баш тарту һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукын туктатып торудан нигезле баш тарту турындагы хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).<br>9. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар һәм мөрәҗәгать итүчегә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү яки мөрәҗәгать итүченең яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә кулга тапшыру.<br>10. Мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә лицензия дубликаты бирү. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 715 номерлы ТР МК карары). |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | 1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга теркәлгән лицензияне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү – гариза теркәлгәннән соң 40 эш көне, шул исәптән:<br>мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү яки мондый хокукны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне;<br>тиешле карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан кишәрлегеннән файдалану хокукы бирүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү; мөрәҗәгать итүчегә теркәлгән лицензияне һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымталарны әзерләү һәм тапшыру (җибәрү) – мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карар чыгарганнан соң 20 эш көне.<br>2. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм гариза бирүчегә лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымтаны бирү – гариза теркәлгәннән соң 40 эш көне, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү яки Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне;<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне; лицензиягә | ТР МКның 715 номерлы карарының 2.5, 2.7, 2.10 пунктлары. |

| | | |
|---|---|---|
| | үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымтаны бирү мөрәҗәгать итүчегә тапшыру – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар чыгарылган көннән башлап 20 эш көне.<br>3. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне мөрәҗәгать итүчегә тапшыру – гариза теркәлгәннән соң 40 эш көне, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне; Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне;<br>мөрәҗәгать итүчегә яңадан рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән лицензия һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе — Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү буенча карар чыгарылган көннән 20 эш көне.<br>4. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан баш тарту турында теркәлгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне.<br>5. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату өлешендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында теркәлгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү һәм лицензияне дәүләт исәбеннән төшерү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне.<br>6. Лицензия дубликаты бирү – гариза теркәлгәннән соң 20 эш көне.<br>Җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензияне, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән, лицензиягә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымтаны, җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне гариза бирүчегә тапшыру (20 эш көне) һәм тиешле документны әзерләү (20 эш көне).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле | 1. Гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза; (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);<br>б) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирү мизгеленә торышын чагылдыра торган һәм эшләрне башлауда планлаштырыла торган сроклар һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турындагы белешмәләрне үз эченә алган аңлатма язуы;<br>в) гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса); | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ статьясы, «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының $35^2$, $35^3$, $35^4$ $35^5$, $35^8$, $35^{81}$ $35^{82}$ статьялары, Тәртипнең 2.1, 4.2, 4.3 4.4 пунктлары, Тәртипкә карата 2 нче кушымта, ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | г) гариза бирүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;<br>д) гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;<br>е) кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);<br>ж) подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);<br>з) гариза бирүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;<br>и) эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре;<br>к) кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;<br>л) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик план күчермәсе (өч нөсхәдә);<br>м) гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан кулланыла торган эчке һәм катнаш («елга-диңгез») елга судноларын «ГЛОНАСС+112» спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС + GPS» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланмалар урнаштыру актының күчермәсе (мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге суднолар файдаланылганда); | |

| | | |
|---|---|---|
| | а) кулланыла торган технологияләр турында белешмәләр, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге һәм аларның мөрәҗәгать итүчегә яисә подрядчыга каравын дәлилләп (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);<br>б) мөрәҗәгать итүченең яисә җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);<br>в) эшләрне башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләре (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);<br>г) су алу скважинасының паспорт күчермәсе (эчә торган су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын эзләү һәм чыгару өчен җир асты суларын чыгару максатында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгәндә);<br>д) җир асты суларын чыгаруның игълан ителгән күләмен исәпләү һәм нигезләү;<br>е) файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнүне уздыру тәкъдимен дә кертеп, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегеннән файдалану шартлары буенча, эшләрнең төрләрен, күләмнәрен, уздыру срокларын, геологик өйрәнүнең көтелгән нәтиҗәләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнәре, шул исәптән файдалы казылма запасларын үстерү буенча да (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында нигезләмә раслау хакында» 2012 елның 3 маендагы 429 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 5 пункты, 7-16 пунктлары, «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ статьясы,<br>ТР МК карарының 4.2 пункты<br>«Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $17^1$ статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);<br>ж) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында мәгълүмат, түбәндәгеләрне үз эченә ала:<br>- җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик төзелеше турында белешмәләр, шул исәптән файдаланыла торган су горизонты турында белешмәләр (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Ширкәтләргә бирелгән очрактан тыш); җир асты суларына булган ихтыяҗны һәм җир асты суларыннан максатчан файдалануны нигезләү (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Ширкәтләргә бирелгән очрактан тыш);<br>- су әзерләү системасын куллану турында мәгълүмат (булган очракта);<br>- су алу схемасы, җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның географик координатлары; җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның конструкцияләре һәм билгеләнеше турында белешмәләр (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Ширкәтләргә бирелгән очрактан тыш);<br>- су алу корылмасын эксплуатацияләү режимының характеристикасы;<br>- чыгарыла торган җир асты суларының санын һәм сыйфатын исәпкә алу һәм контрольдә тоту чаралары турында белешмәләр;<br>- җир асты суларын җир асты байлыклары кишәрлегендә белдерелгән ихтыяҗ күләмендә чыгару мөмкинлеген нигезләү (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Ширкәтләргә бирелгән очрактан тыш).<br>з) файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик план күчермәсе (өч нөсхәдә) (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Ширкәтләргә бирелгән очрактан тыш);<br>и) файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары | |

| | | |
|---|---|---|
| | кишәрлегендә урнашкан су алу скважиналарының географик координаталарын күрсәтеп, вәзгыяти планы (өч нөсхәдә) (Ширкәтләргә эчә торган су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын чыгару өчен җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгәндә). | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә, лицензия килешүенең аерым пунктларын үтәү срокларын үзгәртү зарурлыгына бәйле рәвештә, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктындагы «а», «б» пунктчаларында каралган документлар, шулай ук әлеге регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчасында каралган документлар кирәк, шулай ук:<br>билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм сорала торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталарының координаталары исемлеге белән). Аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>лицензия алынган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә әлеге шартларның үтәлешен раслый торган документлар һәм материалларны теркәп, лицензия килешүе шартларын үтәү турында, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә лицензия алган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә башкарылган эшләрнең төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат<br>- үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатма, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булу вакытын үзгәртү буенча да; җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге арттырылган очракта:<br>файдалы казылма запасларының имин алып бару чикләрен исәпкә алып, файдалы казылма хәзинәләре кишәрлеге чикләрен киңәйтүнең технологик ихтыяҗлары, тау эшкәртмәләренең зарарлы йогынтысыннан саклау зоналары, тау токымнарының зарарлы йогынтысыннан саклау зоналары, табигый объектлар, биналар һәм корылмалар астында саклау циклары контурлары, карьерларның бортлары һәм кисү бортлары һәм җир асты байлыкларының торышына һәм җир өслегенә йогынты ясый торган башка факторлар турында мәгълүмат; | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 26 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | җир асты байлыкларының аскы өлешендә җир асты байлыклары кишәрлегеннән читтә файдалы казылмаларның файдалы казылма запасларының дәүләт яки территориаль балансына (алга таба – баланс) куелган җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә әлеге файдалы казылма ятмасының бер өлеше булып торуына дәлил;<br>- баланска куелган файдалы казылмаларның җир асты байлыклары кишәрлегеннән читтә (җир асты байлыкларының түбән өлешеннән тыш) бу файдалы казылма ятмасының бер өлеше булып торуы турында җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә раслама;<br>- «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $23^2$ статьясы нигезендә килештерелгән дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәләренә ия булган техник проект турында белешмәләр;<br>- Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат территориаль фондына тапшырылган геологик хисап турында белешмәләр. җир асты байлыклары кишәрлегенең мәйданы киметелгән очракта:<br>- җир асты байлыклары кишәрлегенең киметә торган өлешендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә күрсәтелгән һәм аларга карата билгеләнгән тәртиптә дәүләт экспертизасы уздырылган файдалы казылма запаслары булмаса, җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешеннән баш тартуы;<br>- җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә түбәндәгеләргә раслама: җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм (яки) файдалы казылмаларны разведкалау буенча җир асты байлыклары кишәрлегендә башкарылган эшләрнең тиешле төр нәтиҗәләре буенча геологик хисапта расланган җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешен төшереп калдыруга тәкъдим ителә торган геологик объектларны алга таба үзләштерү өчен перспективалы булмавының ачыклануы; әлеге кишәрлекнең җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаручы җир асты | |

| | | |
|---|---|---|
| | байлыкларыннан файдаланучының үз (шул исәптән җәлеп ителгән) акчасы хисабына ачылган файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында белешмәләр;<br>баланска куелган файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре турында белешмәләр.<br>4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә, лицензия бирелгәннән шактый аерылып торган шартлар барлыкка килүгә бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасындагы «а», «б» пунктчаларында каралган документлар кирәк. Аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>лицензия алынган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә әлеге шартларның үтәлешен раслый торган документлар һәм материалларны теркәп, лицензия килешүе шартларын үтәү турында, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә лицензия алган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә башкарылган эшләрнең төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат,<br>лицензия шартларына үзгәрешләр кертү зарурлыгын нигезләү, мөрәҗәгать итүченең кертелүче үзгәрешләрне исәпкә алып җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына кагылышлы тәкъдимнәре белән; билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм соратып алына торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталарының координаталары исемлеге белән) (лицензия участогы чикләренә кагылышлы үзгәрешләр булганда);<br>- мөрәҗәгать итүченең үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензиядә каралган җир асты байлыкларыннан файдалану шартларын тулысынча үтәргә ризалыгы. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү гаризасына түбәндәге материаллар теркәлергә тиеш:<br>- юридик затның гамәлгә кую документларының билгеләнгән тәртиптә | |

| | | |
|---|---|---|
| | расланган күчермәләре; лицензия хуҗасының лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә рөхсәтен раслаучы документ, аны үзгәртеп рәсмиләштерү нигезен күрсәтеп (әгәр гариза тапшырган вакытта лицензия хуҗасы юридик зат статусын саклап калган булса); ышаныч кәгазе, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә гариза мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта;<br>- акционерлар реестрыннан өземтә (гариза тапшыручы акционерлык җәмгыятьләре өчен); барлык кушымталары белән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдаланугa үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия оригиналы; билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм сорала торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталарының координаталары исемлеге белән) (лицензия кишәрлеге чикләренә кагылышлы үзгәрешләр булган очракта).<br>Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының башка затка күчүенең конкрет нигезенә карап, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә түбәндәге документларны һәм белешмәләрне тапшырырга тиеш:<br>1) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аның оешу-хокук формасын үзгәртү юлы белән үзгәртеп корылган очракта:<br>- лицензия алуга дәгъва итүче затның тиешле җир асты кишәрлегенә хокукы билгеле бер рәвештә чагылдырылырга тиеш булган тапшыру акты (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә);<br>2) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аңа башка юридик затны кушу яисә башка юридик зат белән берләштерү юлы белән үзгәртеп корылганда яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат – юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә башка юридик затка кушу нәтиҗәсендә туктатылган очракта:<br>- лицензия алуга дәгъва итүче затның тиешле җир асты кишәрлегенә хокукы билгеле бер рәвештә чагылдырылырга тиеш булган тапшыру акты (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә); мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр;<br>3) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аны бүлү яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә аннан башка юридик затны аерып чыгару юлы белән үзгәртеп корылган очракта, әгәр яңа оештырылган юридик зат җир асты байлыкларыннан файланаучы элеккеге затка бирелгән лицензия нигезендә эшчәнлекне дәвам иттерергә ниятләсә:<br>- лицензия алуга дәгъва итүче затның тиешле җир асты кишәрлегенә хокукы чагылдырылырга тиеш булган бүлү балансы (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә); мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр; 4) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия нигезендә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә эшчәнлекне дәвам иттерү өчен оештырылган яңа юридик затның гамәлгә куючысы булса:<br>- яңа юридик затның Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелүен һәм элеккеге юридик зат – бир асты байлыкларыннан файдаланучының өлеше җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкән вакытта мөрәҗәгать итүче капиталында кимендә яртысын тәшкил итүен раслый торган документларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре; - мөрәҗәгать итүчегә лицензиядә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәт, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә төзекләндерү объектлары мөлкәтеннән файдалану өчен кирәкле мөлкәт тапшырылуы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле | |

| | | |
|---|---|---|
| | эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга (маркшейдер эшләре башкаруга) кирәкле лицензияләр булуы турында белешмәләр;<br>- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр;<br>5) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – төп җәмгыять булып торган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан аның бүлендек җәмгыяте булып торган юридик затка тапшырылган очракта, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – бүлендек җәмгыять булып торучы җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан аның төп җәмгыяте булып торган юридик затка тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыятьләр статусын раслый торган документларны (төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләрен, акционерлар реестрыннан өземтә, хуҗалык итүче җәмгыятьләр арасындагы килешү күчермәсен яки Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә бүлендек җәмгыять тарафыннан кабул ителә торганк арарларны төп җәмгыять тарафыннан билгели алу мөмкинлеген раслый торган документларның күчермәләрен) тапшыра;<br>6) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте булып торган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан шул ук төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте булып торган юридик затка тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыятьләр статусын раслый торган документларны (төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләрен, акционерлар реестрыннан өземтә, хуҗалык итүче җәмгыятьләр арасындагы килешү күчермәсен яки Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә бүлендек җәмгыять | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан кабул ителә торганк арарларны төп җәмгыять тарафыннан билгели алу мөмкинлеген раслый торган документларның күчермәләрен) һәм төп җәмгыятьнең лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә язмача күрсәтмәсен тапшыра.<br>Шулай ук мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга карата белдерелә торган таләпләргә туры килүе турында, анда җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен тиешле финанс һәм техник чараларның булуы һәм квалификацияле белгечләрнең булуы турында белешмәләр, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясендә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәтнең, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә урнаштырылган объектлар мөлкәте составыннан да, мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган булуы турында мәгълүматлар тапшырылырга тиеш; 7) эшкуарлык эшчәнлеге субъекты тарафыннан «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законда каралган тәртиптә банкрот предприятие (җир асты байлыкларыннан файдаланучы) милеге (мөлкәт комплексын) сатып алынган очракта:<br>- мөлкәт сатып алучының Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик зат булуы турында, белешмәләр җир асты байлыкларыннан файдаланучыга карата Россия Федерациясе җир асты байлыклары турындагы законнарда белдерелә торган квалификация таләпләренә җавап бирүе турында белешмәләр; - лицензия хуҗасына карата банкротлык процедурасы үткәрелүен раслаучы документлар, шул исәптән лицензия хуҗасына карата банкротлык процедурасы башлануы турында суд карары күчермәсе;<br>- лицензия иясе булган банкрот предприятиесенең мөлкәтен (мөлкәт комплексын) сатып алуны раслаучы документлар (оригиналлар яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә) һәм бу мөлкәтнең тиешле җир асты кишәрлегеннән файдалануга бәйле булуын раслаучы документлар (оригинал яисә расланган күчермә). | |

| | | |
|---|---|---|
| | 8) консеция килешүе, кайнар су, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларына карата, мондый системаларның «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка объектларына карата аренда килешүе һәм башка төрле килешүләр төзелгән очракта:<br>- концессия килешүе күчермәсе.<br>6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату һәм лицензияне дәүләт исәбеннән төшерү өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, белдерелгән срокка кадәр кимендә алты ай алдан, түбәндәге документларны теркәп, рәсми мөрәҗәгать тапшырырга кирәк:<br>- җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышын чагылдыручы, гариза тапшыру мизгеленә һәм ятманы эксплуатацияләү эшләрен төгәлләгәндә, ятманы эшкәртүнең техник проектында каралган эшләрне башлау вакыты һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр үз эченә алган аңлатма язуы,<br>- лицензия килешүендә билгеләнгән барлык йөкләмәләрне һәм шартларны үтәү, әлеге йөкләмәләрнең һәм шартларның үтәлүен раслый торган документлар һәм материаллар кушымтасы белән, шулай ук предприятиене лицензия килешүе белән ликвидацияләү һәм консервацияләү, гариза биргән датага торыш буенча, шушы йөкләмәләрнең һәм шартларның үтәлешен раслый торган документлар һәм материаллар белән мәгълүмат.<br>Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә (мөрәҗәгать итүченең мөһере белән яки нотариаль яктан) таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында | |

| | | |
|---|---|---|
| | урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>- почта юлламасы белән. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. «Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында өземтә яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язулары кәгазе;<br>- гариза тапшыручы шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры язулары кәгазе;<br>- мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән);<br>- салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән);<br>- мөрәҗәгать итүченең һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә җәлеп ителә торган подрядчыларларның лицензияләре күчермәләре;<br>- җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт контракты күчермәсе (күрсәтелгән эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарган очракта);<br>- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халык саулыгы өчен куркынычсыз булган су объектыннан файдалану шартларына туры килүе турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттән (алга таба – Роспотребнадзор) санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе;<br>- дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акчаларның алынуы турында турында белешмәләр (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе). | «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының $35^2$ статьясының 3, 6 абзацлары;<br>Тәртипнең 4.5 пункты;<br>«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 13 августындагы 674 |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны яки гамәлләрне башкаруны;<br>210-ФЗ санлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны; дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен югарыда аталган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый | номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеше, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләнмәгән. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1. Гаризаны билгеләнгән таләпләрне бозып тапшыру.<br>2. Мөрәҗәгать итүче үзе турында беләторып ялгын белешмәләр тапшырган очракта.<br>3. Мөрәҗәгать итүче эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса.<br>4. Әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта, монополиягә каршы таләпләр үтәлмәячәк булса.<br>- мөрәҗәгать итүчегә, әгәр мондый үзгәртеп рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән шартларга һәм таләпләргә җавап бирмәсә, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тартыла. | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 14 статьясы<br>Тәртипнең 2.7 пункты, 715 номерлы ТР МК карарының 4.8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасының күләме Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән:<br>- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү – 7500 сум;<br>- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 750 сум;<br>- үзгәрешләр кертү (җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогы озайтылган очракта) – 750 сум.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү гариза бирүче тарафыннан акча күчерү юлы белән, акчасыз исәп-хисап рәвешендә гамәлгә ашырыла.<br>Акча күчерү өчен реквизитлар:<br>Алучы: ТР буенча РФ ФМХИ (ТР Экология министрлыгы)<br>ИНН 1659036508 КПП 165901001<br>И-х/с 40101810800000010001 Россия<br>Банкының ТР МБ ГРКЦ Казан шәһәре БИК<br>049205001 ОКТМО 92701000 (Казан) КБК<br>70110807082011000110<br>Түләүнең билгеләнеше: җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү / җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү / җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту өчен дәүләт пошлинасы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документка үзгәрешләр кертелгән очракта, Министрлык һәм (яки) Министрлыкның вазыйфаи заты гаебе белән кертелгән хаталарны төзәтү өчен гариза бирүчедән түләү алынмый | РФ Салым кодексының 333.33 статьясындагы 92 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә дә | Гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары; Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү | закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы | Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>Министрлык бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин ителүе;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша | |

| | | |
|---|---|---|
| күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы. | җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Министрлык сайтыннан алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшыру эшләре) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Мөрәҗәгать итүчегә консультация Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә бирелергә мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru).<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып та, күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru).<br>Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өлешендә; документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

Министрлык карарын әзерләү һәм раслау:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында; җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында;

түбәндәгеләрне әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыру:

җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымта;

җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар;

лицензия дубликатын бирү;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, кәгазьдә яисә почта аша Министрлыкка гариза тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә этәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушыла, гариза почтадан җибәрелгән, – мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

3.32. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече:

гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итү һәм «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон документ әйләнеше) терки; мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра; гаризаны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны, аларны карап тикшерүне оештыру өчен, электрон документ әйләнеше системасы аша Министрга тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырылган документлар.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм министр урынбасарына (җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып бара торган) карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.3.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карап тикшерү өчен Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесенә (алга таба – Идарә җитәкчесе) юнәлдерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесенә карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. Идарә җитәкчесе гаризаны карый һәм Бүлек җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. Бүлек җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы башкаручыны билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.4. Министрлык карарын әзерләү һәм раслау:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында; җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

лицензия дубликаты бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында; лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

3.4.1. Бүлек белгече алынган гариза һәм аңа теркәлгән документлар нигезендә:

әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килү-килмәвенә карата тапшырылган документларга анализ ясый;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси инициатива буенча тапшырылмаган булсалар, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган тиешле дәүләт органнарыннан әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрә:

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында белешмәләр яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язуы кәгазен бирү турында;

- гариза тапшыручы шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры язуы кәгазен бирү турында;

- салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен бирү турында;

- мөрәҗәгать итүченең һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә җәлеп ителә торган подрядчыларларның лицензияләре күчермәләрен бирү турында;

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм су объектыннан файдалануның халык сәламәтлеге өчен куркынычсызлык шартларына туры килүе хакында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында (Роспотребнадзор);

- дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акчаларның алынуы турында турында белешмәләр бирү турында (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе);

- законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр бирү турында (Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсе, дәүләт күзәтчелегенең вәкаләтле органнары).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: анализланган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүче затларның белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгать нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясының 3 пункты нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) законнарда билгеләнгән срокта бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: алынган документлар (белешмәләр) яки Министрлыкка җибәрелгән баш тарту турында белдерү.

3.4.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне әзерли һәм Бүлек җитәкчесенә (ул булмаган очракта – Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган затка) җибәрә:

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, – Министрлык карары проекты:

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында; җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

- лицензия дубликаты бирү турында;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, – Министрлык карары проекты:

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

- лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң 9 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән Министрлык карары проекты.

3.4.4. Бүлек җитәкчесе Министрлыкның карары проектын килештерә һәм Министрлыкның каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә (алга таба – Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе) килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм каты файдалы казылма геологиясе бүлеге җитәкчесенә килештерү өчен юлланган Министрлык карары проекты.

3.4.5. Каты файдалы казылма геологиясе бүлеге җитәкчесе (ул булмаган очракта – каты файдалы казылмалар бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) Министрлык карары проектын килештерә һәм килештерү өчен Идарә җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм Идарә җитәкчесенә килештерү өчен юлланган Министрлык карары проекты.

3.4.6. Идарә җитәкчесе (ул булмаган очракта – Идарә җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) Министрлык карары проектын килештерә һәм Министрлыкның хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә (алга таба – хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе) килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән Министрлык карары проекты.

3.4.7. Хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе (ул булмаган очракта – хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) Министрлык карары проектын килештерә һәм министр урынбасарына (җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы) (алга таба – министр урынбасары) килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм министр урынбасарына килештерү өчен җибәрелгән Министрлык карары проекты.

3.4.8. Министр урынбасары (ул булмаган очракта – министр урынбасары вазыйфаларын башкара торган зат) Министрлык карары проектын килештерә һәм имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен министрга җибәрелгән Министрлык карары проекты (мөрәҗәгать итүче адресына хат, боерык).

3.4.9. Министр (ул булмаган очракта – министр вазыйфаларын башкара торган зат) Министрлык карарын раслый:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

лицензия дубликаты бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның расланган карары.

3.5. Түбәндәгеләрне әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыру:

җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымта;

җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензия;

лицензия дубликаты;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат;

лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында хат.

3.5.1. Министр тарафыннан расланган мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясен үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында карар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар теркәлгәннән соң Министрлыкның документлар үтәлешен тикшереп тору бүлеге аша мөрәҗәгать итүчегә хат рәвешендә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүче адресына җибәрелгән хат.

3.5.2. Министр тарафыннан расланган, мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турында, җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында, лицензия бирү турында Министрлык боерыгы формасында расланган карар, теркәлгәннән соң, документлар үтәлешен тикшереп тору бүлеге аша аны әзерләгән Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә боерык формасында җибәрелгән карар.

3.5.3. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия әзерләү бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымталар әзерли һәм Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү бүлегенә җир асты байлыкларыннан файдаланганда икътисадый исәпләмә ясау турында рәсми мөрәҗәгать юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда икътисадый исәпләмә ясау турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгать.

3.5.4. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең икътисадый исәпләмәсен әзерли. Әзер икътисадый исәпләмә хезмәт язуы белән Бүлеккә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең әзерләнгән икътисадый исәпләмәсе.

3.5.5. Икътисадый исәпләмә алынганнан соң Бүлек белгече түбәндәгеләрнең проектын әзерли:

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия һәм лицензия килешүе;

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензиягә кушымта;

кушымта белән, мөрәҗәгать итүче адресына хат.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 12 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.6. Бүлек белгече әзерләнгән лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензия кушымтасы проектын килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.7. Бүлек җитәкчесе (ул булмаган очракта – Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм килештерү өчен каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә җибәрелгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.8. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе (ул булмый торган очракта – каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм килештерү өчен Идарә җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм Идарә җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.9. Идарә җитәкчесе (ул булмый торган очракта – Идарә җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм килештерү өчен хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә җибәрелгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.10. Хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе (ул булмый торган очракта – хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкара торган зат) лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хокукый бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен министр урынбасарына юлланган лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.11. Министр урынбасары (ул булмый торган очракта – министр урынбасары вазыйфаларын башкара торган зат) лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан
соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзалау өчен әзерләнгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.12. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә әзерләнгән лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты турында һәм турыдан-туры Министрлыкта аны шәхсән имзалау мөмкинлеге турында хәбәр итә, мөрәҗәгать итүченең Министрлыкта турыдан-туры имзалау мөмкинлеге булмаган очракта, Бүлек белгече лицензия проектын һәм лицензия килешүе проектын яки лицензиягә кушымта проектын имзалау өчен почта буенча (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы юллама итеп) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта шәхсән имзалаган очракта, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 эш көне эчендә, лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты мөрәҗәгать итүче адресына почта буенча рәсми хат итеп (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы юллама итеп) җибәрелгән очракта гамәлгә ашырыла. Имзалау буенча вакыт озынлыгы дәүләт хезмәте күрсәтү чорына керми.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзаланган һәм имзалау өчен министрга юлланган лицензия проекты һәм лицензия килешүе проекты яки лицензиягә кушымта проекты.

3.5.13. Министр (ул булмый торган очракта – министр вазыйфаларын башкара торган зат) түбәндәгеләрне имзалый:
җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия һәм лицензия килешүе;
җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензиягә кушымта.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга министр имзалаган лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта мәгълүмати геология ресурслары һәм геологик мохиткә мониторинг бүлегендә теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.12 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр кул куйган һәм мәгълүмати геология ресурслары һәм геологик мохиткә мониторинг бүлегендә теркәлгән лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта.

3.5.14. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә министр кул куйган лицензияне һәм лицензия килешүен, лицензиягә кушымтаны кулына тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган, теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта.

3.6. Лицензия дубликаты бирү.

Лицензия документлары югалган очракта яисә бозылганда, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

3.6.1. Гариза кабул итү һәм теркәү.

Лицензия дубликаты бирү өчен гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү. Бүлек белгече:

әлеге Регламентның 3.5.1-3.5.2 пунктлары нигезендә процедураларны гамәлгә ашыра; билгеләнгән формадагы бланкта лицензия дубликаты рәсмиләштерә һәм анда «Дубликат» штампын куя яисә, лицензия дубликаты бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хат проекты әзерли; әзерләнгән документлар проектларын министрга (ул вәкаләт биргән затка) кул кую өчен җибәрә.

3.6.1-3.6.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар гариза кергәннән соң 19 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга имзалау өчен җибәрелгән документларның проектлары яки лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында хат проекты.

3.6.3. Министр (ул вәкаләт биргән зат) лицензия дубликаты бирү турындагы боерыкны раслый, лицензия документларының рәсми дубликатын имзалый, аны Министрлык мөһере белән раслый яки лицензия дубликаты бирүдән баш тарту

турындагы хатка, сәбәпләрен күрсәтеп, кул куя. Имзаланган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган документлар.

3.6.4. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә, лицензия дубликаты бирү датасы һәм вакыты турында хәбәр итә; лицензияләр реестрына лицензия дубликаты бирү турында белешмәләр кертә; лицензия дубликаты күчермәсен мөрәҗәгать итүченең лицензия эшенә тегеп куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар министр тарафыннан документларга кул куелган көнне гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.6.5. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, бирелгән лицензияләр журналында лицензия дубликаты алу турында кул куйдыртып, лицензия дубликатын тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган лицензия дубликаты.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ; техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә җибәрелә.

3.7.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша,

Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала. Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

- эш башкарылуына;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру вакытлары һәм тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

3) Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшырылуы каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

- мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләре.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымтак

Үрнәк

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 12 гыйнварындагы 715 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

____________________________________

Фамилиясе, исеме, атасының исеме.

Аукцион үткәрмичә генә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы алу өчен гариза

________________________________________________

җир асты байлыклары кишәрлегенең (ятмасының) атамасы

1. Мөрәҗәгать итүче

________________________________________________

юридик зат атамасы, җитәкчесенең вазыйфасы, Ф.И.А

2. Дәүләт теркәве кодлары һәм реквизитлары:

________________________________________________

ИНН, ОГРН, ОКПО, ОКОНХ, ОКОГУ, БИК, ОКАТО, ОКВЭД һ.б.

3. Юридик адрес:

________________________________________________

Почта адресы:

________________________________________________

телефон: (код)____________________, телефакс: (код) ____________________

e-mai1 (булган очракта):____________________________________

4. Мөрәҗәгать итүченең эшкуарлык максаты, билгеләнгән эшләр исемлеге:

жир асты байлыкларыннан файдалану максатлары, гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеге нигезендә файдалы казылма төре күрсәтелә

эшләрне үткәрү вакыты: ______________________________

5. Банк реквизитлары: ______________________________
счет номерлары, банк исемнәре

1) ______________________________
2) ______________________________
3) ______________________________
. .) ______________________________
...) ______________________________

6. Теркәлә торган документлар исемлеге:
«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җир асты байлыкларыннан файдалану төренә карап, документлар.

Предприятие җитәкчесе: ______________________________

имза, фамилия, исем, ата исеме м. у.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

______________________________

______________________________

______________________________

(җитәкченең ФИА, предприятие исеме) лицензия сериясе __________№ ____________җир асты байлыклары кишәрлеге

______________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______

(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:

________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:

________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ____________________________________________

2. ____________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:

e-mail:__________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

- _____________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры<br>Шадриков Александр Валерьевич | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары<br>Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | 267-68-26 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе<br>Вахитов Самат Таһир улы | 267-68-60 | Samat.Vahitov@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе<br>Чинарев Алексей Михайлович | 267-68-68 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте күрсәткәндә контрольне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларының реквизитлары

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге | 264-77-46 | pisma@tatar.ru |